КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 февраль г.Казань № 83

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 февраль, 131 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның [3] статьясындагы 92 пункты һәм «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның 165 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин аерым категориядәге гражданнар исемлеге һәм Татарстан Республикасында мондый кооперативлар әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнар исемлекләренә күрсәтелгән гражданнарны кертү нигезләре;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләре.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә хокуклы гражданнарның аерым категорияләре исемлекләрен формалаштыру кагыйдәләрен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә хокуклы гражданнар исемлекләрен формалаштыру кагыйдәләрендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләре»;

1 пунктта «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы һәм «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы федераль законнар белән (алга таба - исемлекләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карары белән расланган Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин аерым категориядәге гражданнар исемлеге һәм Татарстан Республикасында мондый кооперативлар әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнар исемлекләренә күрсәтелгән гражданнарны кертү нигезләренең 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән гражданнар исемлекләргә (алга таба - Исемлек) кертелүгә хокуклы.»;

3 пунктта «, әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Исемлекләргә кертү өчен Исемлекнең 1.1 пунктының «а» - «г» пунктчаларында һәм 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар әлеге пунктта күрсәтелгән документларны аларның эш урыны буенча торак мәсьәләләре буенча комиссиягә (алга таба - Торак комиссиясе), өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар - яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органына (алга таба - җирле үзидарә органы) тапшыралар.

Исемлекләргә кертү түбәндәге документлар һәм белешмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча исемлеккә кертү турында гариза (алга таба – гариза);

б) гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документларның күчермәләре;

в) гражданның гаилә составын раслый торган документларның күчермәләре ("Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык), моңа әлеге пунктның «з» һәм «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлар керми;

г) җирле үзидарә органының гражданны торак урынына мохтаҗ дип тану турындагы карарының күчермәсен;

д) дәүләт кадастр исәбен алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны гамәлгә ашыручы органнан гражданда һәм аның гаилә әгъзаларында булган күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр;

е) Исемлекнең 1.1 пунктындагы «а» – «г» пунктчаларында һәм 1.2 пунктында күрсәтелгән оешмаларда (учреждениеләрдә) гражданның кимендә биш ел гомуми эш стажын раслый торган документлар (белешмәләр);

ж) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны (гражданга һәм аның гаилә әгъзаларына) эшкәртүгә ризалык;

з) чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;

и) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән баланы уллыкка алу турында таныклыклар;

к) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар өчен гаилә әгъзасы итеп тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карарлары (билгеләмәләре яисә карарлары).

Әлеге пунктның «а», «б», «ж» - «к» пунктчаларында күрсәтелгән документлар гражданнар тарафыннан тапшырыла.

Әлеге пунктның «в» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар (белешмәләр) гражданнар тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылырга мөмкин, ә күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) тапшырмаган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә соратып алына.

Оешманың (учреждениенең) торак комиссиясе, җирле үзидарә органы әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнарга, аларның исемлеген һәм тапшыру датасын күрсәтеп, документлар алу турында алу кәгазе бирә.»;

6 пунктта «учреждениеләр оештыра» сүзләрен «оешмалар (учреждениеләр), җирле үзидарә органы оештыра» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта:

беренче абзацта «учреждениеләр10 көн эчендә кабул итә» сүзләрен «оешмалар (учреждениеләр), җирле үзидарә органы гаризаны биргән көннән алып 10 көн эчендә кабул итә» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 17 июнь, 414 нче карары белән расланган «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин аерым категориядәге гражданнарның" сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктына «, җирле үзидарә органы соравы буенча алынырга мөмкин булган документлардан тыш» сүзләрен өстәргә;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Исемлекнең 1.1 пунктындагы «а» - «г» пунктчаларында һәм 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар исемлекләргә Торак комиссиясе тарафыннан, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар - яшәү урыны буенча җирле үзидарә органы тарафыннан кертелә. Күрсәтелгән исемлекләр әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелә.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре, Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәдәният учреждениеләре исемлекләрне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба - тармак министрлыкларына) тапшыралар.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Муниципаль мәгариф оешмалары, муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләре, муниципаль мәдәният учреждениеләре исемлекләрне оешманың (учреждениенең) урнашкан урыны буенча җирле үзидарә органнарына тапшыралар.»;

13 пунктта «торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14 пунктта «учреждениеләр» сүзен төшереп калдырырга.

16 пунктта «15 октябрьгә кадәр» сүзләрен «ел саен, 15 октябрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымтада:

нумерация исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләренә 1 нче кушымта»;

«Торак комиссиясе җитәкчесенә» сүзләрен «Торак комиссиясе (җирле үзидарә органы) җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

«Ф.И.Ә.И.» сүзләрен «Ф.И.Ә.И. (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

"Татарстан Республикасында «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы федераль закон, «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы федераль закон белән (кирәклесенең астына сызарга)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтада:

нумерация исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләренә 2 нче кушымта»;

“Учреждение җитәкчесе” сүзләрен “Оешма (учреждение, җирле үзидарә органы) җитәкчесе” сүзләренә алмаштырырга;

«Ф.И.Ә.И.» сүзләрен «Ф.И.Ә.И. (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак-төзелеш кооперативы әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнар исемлеге»;

5 графа исемендә «бюджет» сүзен «гражданнар» сүзенә алмаштырырга;

7 графа исемендә «учреждениеләр» сүзен «оешмалар (учреждениеләр)» сүзләренә алмаштырырга;

8 графа исемендә «хокуклар» сүзен «көчемсез милек» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга карата 6 һәм 7 графалар тутырылмый.»;

әлеге Кагыйдәләргә 3 нче кушымтада:

нумерация исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләренә 3 нче кушымта»;

«Ф.И.Ә.И.» сүзләрен «Ф.И.Ә.И. (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак-төзелеш кооперативы әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнарның җыелма исемлеге ____________________________________________

(тармак министрлыгы, муниципаль берәмлек

____________________________________________________________________»;

атамасы)

5 графа исемендә «бюджет» сүзен «гражданнар» сүзенә алмаштырырга;

7 графа исемендә «учреждениеләр» сүзен «оешмалар (учреждениеләр)» сүзләренә алмаштырырга;

8 графа исемендә «хокуклар» сүзен «күчемсез милек» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга карата 6 һәм 7 графалар тутырылмый.»;

әлеге Кагыйдәләргә 4 нче кушымтада:

нумерация исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнарның исемлекләрен төзү кагыйдәләренә 4 нче кушымта»;

«Ф.И.Ә.И.» сүзләрен «Ф.И.Ә.И. (соңгысы - булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча торак-төзелеш кооперативы әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнарның җыелма исемлеге ____ елга»;

5 графа исемендә «бюджет» сүзен «гражданнар» сүзенә алмаштырырга;

7 графа исемендә «учреждениеләр» сүзен «оешмалар (учреждениеләр)» сүзләренә алмаштырырга;

8 графа исемендә «хокуклар» сүзен «күчемсез милек» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга карата 6 һәм 7 графалар тутырылмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 17 июнь, 414 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 февраль, 83 нче
карары редакциясендә)

# Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин аерым категориядәге гражданнар исемлеге һәм Татарстан Республикасында мондый кооперативлар әгъзалыгына кабул ителергә хокукы булган гражданнар исемлекләренә күрсәтелгән гражданнарны кертү нигезләре

## I. Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителергә мөмкин булган аерым категориядәге гражданнар исемлеге

1.1. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына Татарстан Республикасында гражданнарның түбәндәге категорияләре кабул ителергә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәгариф оешмаларында, муниципаль мәгариф оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

б) Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

б) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларында, муниципаль сәламәтлек саклау оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

а) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә, муниципаль мәдәният учреждениеләрендә эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

д) өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар.

1.2. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында төзелә торган торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына Татарстан Республикасында гражданнарның түбәндәге категорияләре кабул ителергә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәгариф оешмаларында яки муниципаль мәгариф оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

б) Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

б) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт сәламәтлек саклау оешмаларында яки муниципаль сәламәтлек саклау оешмаларында эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар;

а) Татарстан Республикасы карамагындагы дәүләт мәдәният учреждениеләрендә яки муниципаль мәдәният учреждениеләрендә эшләү төп эш урыны булып торган гражданнар.

II. Гражданнарны торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына кабул ителү хокукына ия гражданнар исемлекләренә кертү нигезләре

2.1. Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларына әлеге Исемлекнең 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән гражданнар кертелә, бер үк вакытта түбәндәге нигезләр булганда:

гражданның әлеге Исемлекнең 1.1 пунктындагы «а» - «г» пунктчаларында һәм 1.2 пунктында күрсәтелгән оешмаларда (учреждениеләрдә) эшчәнлегенең гомуми стажы кимендә биш ел тәшкил итә (әлеге Исемлекнең 1.1 пунктындагы «а» - «г» пунктчаларында һәм 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар өчен);

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк бала (шул исәптән уллыкка алынган, кызлыкка алынган) булу (әлеге Исемлекнең 1.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен);

гражданның «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон гамәлгә кертелгәннән соң индивидуаль торак төзелеше хокукында индивидуаль торак төзелеше яисә аренда өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән җир кишәрлеге юк;

граждан торак урынына мохтаҗ дип танылган;

граждан аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларында катнашмый.

___________________________